**Тәрбия**

# Балаларга үгет-нәсыйхәт

### ТУГАННАР

Туганнарыгыз — ата вә аналарыгыз соңында иң якын кешеләрегездер. Шуның өчен алар белән һәрвакыт әдәпле вә мәрхәмәтле булыгыз! Боларның олыларын ата вә ана урынында санап, итагатьле булыгыз вә сүзләрен тыңлап гамәл итегез! Кечеләренә шәфкатьле булып, аларны бер дә рәнҗетмәгез вә каты күңелле булмагыз. Оятсызлык вә тәрбиясезлектә күчергеч булып күренмәгез, аларны сүкмәгез, кулларында булган нәрсәләрне тартып алмагыз. Чөнки болай итү аларның каннары бозылуга вә ата-ананы ачуландыруга сәбәп булыр.

Туганнарыгызда ярамаган бер эш күренер булса — яхшы сүз белән: «Болай булмагыз, гаеп эш бит!»— дип тыегыз вә әлеге эшнең килешмәгәнен аңлатып күрсәтегез, гүзәл юлга күндерегез.

Туганнарыгыз өстеннән ата вә аналарыгызга сүз әйтмәгез, чөнки болай булган балалар, мондый эшләргә гадәтләнеп, олыгайгач та сүз йөртүче булырлар. Бәлки булса — гүзәл эшләрне сөйләгез!

Туганнарыгызның әйтүләрен көтеп тормыйча, һәр эшләрендә ярдәмче булыгыз, кулыгыздан килгән изгелекләрне бер дә алардан кызганмагыз!

Туганнарыгызның серләрен гүзәл саклагыз, аларга шатлыклы хәбәрләр сөйләп (әгәр дә аларга зарар китерәчәк булмаса), яманнарын сөйләмәгез! Сүз вә гамәлләрегез белән аларга ихласлы булыгыз, гаепләрен яшерегез, һәрвакытта ачык йөз вә киң күкрәк белән каршы алыгыз!

Кайбер балалар булыр ки: аталары вафат булгач, мал бүлү хакында туган вә кардәшләр белән бозылышырлар, бер-берсе хакында әдәпсез мөгамәләдә булырлар, кыйммәтле вакытларын вә газиз малларын әрәм итәрләр, үзләренең кан вә җан кардәшләрен рәнҗетеп, читләрнең корсакларын туйдырырлар, бу юлда үзләре дә бәхетсез булырлар, ата вә аналарының да исемнәрен хөрмәтсез итәрләр, гаилә вә кабиләләрне мәсхәрәлектә калдырырлар. Сез үскәч, мондый балалар кебек булмагыз, гаеп эштер! Бәлки, туганнарыгыз белән һәрвакытта берлектә булыгыз! Нәҗесне (бозык холык вә ачу сәбәпләрен) һәрвакыт туфрак астына күмегез, болай булганда аз мал да күп күренер, кыска гомер дә бәрәкәтле булыр.

***Риза ФӘХРЕТДИН.***
***(«Нәсыйхәт» китабыннан)***

**Сорау-җавап**

# Хәрәм вә золым булган эшләр

- **Безнең татар халкында явыз көнчелек бар. Элекке дусты яки бергә укыган иптәше берәр дәрәҗәле исемгә лаек булса, ул моңа борчылып, төннәр буе йоклый алмый ята. Берәр танышы белән очрашса, тизрәк элекке дустының «гөнаһларын» чыгарып сала, аны хурлый, кимсетә башлый, ачудан йөрәге яна. Коръәндә көнчелек турында аять яки сүрә бармы?**

- Коръәндә көнчелек турында шактый аять-кәримәләр бар, менә шуларның берсе — «әл-Фәләкъ» сүрәсенең 5 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Үә миң шәрри хәә-сидин изәә хәсәде», ягъни «Көнчел вә хөсетле кешенең мәкереннән Аллаһыга сыенамын».

Равиләр көнчелек турында шундый бер хикәят сөйлиләр: «Борынгы заманда ике гарип бар иде. Берсе саңгырау, берсе сукыр иде. Ул ике гарип бик дуслар иде. Боларны бер шайтан дуслыкларыннан аерып сугыштыру нияте белән бик тырышып йөрде. Һич чара таба алмыйча, гаҗиз булды, әмма аларны сугыштыра алмады. Ахырда, шайтан боларны сугыштыра алмагач, бер явыз кеше янына килде һәм әйтте: «Син явыз, безнең дустыбыз! Шул ике гарипне дуслыкларыннан аерып сугыштыр. Шуны башкара алсаң, хакына ни теләсәң, шуны миннән алырсың», — диде.

Менә ул явыз кеше гарипләрнең янына килде, саңгырау гарипнең яңагына ике мәртәбә бик каты сукты һәм: «Монысы юлдашыңа булсын!» — дип әйтте. Бу сүзләрне сукыр юлдашы читтәрәк, бер тарафта тыңлап тора иде. Аннан соң ул явыз кеше болар яныннан китте. Сукыр саңгырау иптәше янына килде һәм әйтте: «Ул кеше сиңа ни бирде, мин аның: «Монысы юлдашыңа булсын!» — дигән сүзен ишетеп калдым. Саңгырау әйтте: «Һичнәрсә дә бирмәде, мәгәр ике яңагыма бик каты сукты, «Берсе — сиңа, берсе юлдашыңа булсын», — дип». Аннан соң ул сукыр әйтте: «Ул биргән нәрсә кыйммәтле вә шәрәфле нәрсә булганга, минем хакымны бирмисең, яшереп үзеңә алып калмакчы буласың», — диде.

Шулай итеп, сукыр саңгырау иптәшенең сүзенә ышанмады. Ахырда ике дус тарткалаштылар һәм сугышып киттеләр. Дуслыкларыннан берни дә калмады».

Бәс, адәм угылы вә кызы бер-берсен котыртуда, вәсвәсә кылуда шайтаннан да явызрак икәнлеге мәгълүм булды. Шундый начар эшләрдән, көнчелектән, Раббым, безне Үзең сакла.

Кешеләрдән үзеңдә булмаган нәрсәләре булуына көнләшеп, аларга аяк чалырга юл эзләү, аларның бәхетләрен бикләргә тырышу — бигрәк яман эш. Мөселман булган адәмнең эшләрен күпсенгән кешене кяферләр үзләре дә яратмыйлар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам көнләшүчеләр турында болай ди: «Әл-хәсиду лә йәдхулүл-җәннәтә».

Мәгънәсе: *«Кешедән көнләшүче оҗмахка кермәс».*

Менә шушы хәдистән дә көнләшүнең никадәр начар икәнен аңларга мөмкин. Шулай ук бер мөселман кешегә бәла килсә, үз башыңа килгән кебек аңа ярдәм итәргә тиешсең. Үзеңдә булган бер нәрсәнең башка кешедә булмавын теләү, башкаларда булуын күпсенү дә көнләшүгә керә. Мөселман булган кеше үзендә булган бәхет, байлык, гыйлем кебек нәрсәләрнең башкаларда да булуын чын күңелдән теләргә тиеш. Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам бу турыда болай дигән: «Ләә йуъминү әхәдикүм хәттә йүхиббү лиәхыйһи мәә йүхиббү линәфсиһи».

Мәгънәсе: *«Үзең сөйгән нәрсәнең мөселман булган кардәшеңдә булуын теләгәнгә кадәр, һичберегез чын мөселман булмассыз».*

Шуның өчен чын мөселман кара көнләшү белән көнләшмәскә тиеш. Ягъни бер мөселман икенче мөселман кардәшенә тик изге теләкләр теләп, хәерле дога кылырга тиеш. Моны күреп, ишетеп торган рәхмәт фәрештәсе шушы дога кылучы мөселманга: «Әй, Раббым Аллаһы, бу мөселман бәндәнең кардәшенә кылган догасы кабул булсын иде», — дип дога кылыр.

- **Күршем бик явыз, ул миңа гел явызлык кыла. Миңа нишләргә?**

- Атаклы Ислам галиме Хәсән әл-Басрый исемле кешенең бер яһүди күршесе бар иде. Һәрдаим Хәсәннең йөри торган юлына пычрак нәрсәләр, чүпләр, чәнечкеле үсемлекләр ташлый иде. Көннәрдән бер көнне бу яһүди Хәсәннең йортына килеп керде һәм әйтте: «И, Хәсән! Син нинди кешесең? Минем сине җәфалар өчен кылган явыз гамәлләремә сабыр итәсең, кереп кычкырышып-талашып, якалашып йөрмисең, сабыр итәсең», — диде.

Хәсән аңа тыныч кына: «Безнең шәригатебездә: «Күршесе белән талашып, ызгышып торган кеше оҗмахтан мәхрүм калыр», — дип язылган», — диде. Яһүд озак кына уйлап, басып торды һәм: «Әй, Хәсән, сезнең шәригатегез бик яхшы икән», — дип, иман китереп мөселман булды.

Бу кыйссадан гыйбрәт ал: яхшылар, сабырлар үзләренең күркәм гамәлләре белән кяферне иманга китерделәр.

Әлхәмду лилләһи раббил галәмин. Үәл гакыйбәтү лил-мүттәкыйн. Үәс-саләтү үәссәламү галә әлиһи үә сахбиһи әҗмәгыйн.

Коръән-Кәримдә Аллаһы Тәгалә бик күп урында сабырлык хакында хәбәр бирә вә һәрбер иманлы бәндәне сабырлыкка чакыра. «Ән-Нәхел» сүрәсенең 96 нчы аятендә сабырлык хакында болай диелә: «Мәә гиңдәкүм йәңфәду үә мәә гиңдәллааһи бәәкый. Үә ләнәҗзийән-нәлләзиинә сабәруу әҗераһүм биәхсәни мәә кәәнүү йәгмәлүүн».

Мәгънәсе: *«Сезнең кулыгызда булган нәрсәләр бетәчәк, әмма Аллаһы Тәгалә кулында булган барча нәрсәләр мәңге калырлар. Аллаһы Тәгалә кушканча яшәп вә Ул кушканча Ислам динен тотып бөтен авырлыкларны күтәрүче сабыр мөэминнәргә, әлбәттә, кылган изге гамәлләренә караганда да яхшырак итеп әҗерен кайтарырбыз».*

Безнең дөньябыз — бер имтихан дөньясыдыр. Адәм баласы дөньяда яшәгәндә, төрле хәлләр белән очраша. Аларның бәгъзесе бәндәне шатландырыр, кайсыберләре зур кайгыга салыр.

Мөселманнарга шатлык вә бәхет килгәндә шөкрана кылу, ягъни «Әлхәмдүлилләһ» дип әйтү, шөкер намазы уку, кайгы төшкәндә хәүф намазы уку лазем.

«Әл-Гыймран» сүрәсенең 200 нче аятендә авырлыкларны бергәләп күтәрү хакында болай әйтелә: «Йәә әййүһәлләзиинә әәмәнүс-бируу үә саабируу үә раабитуу үәт-тәкул-лааһә ләгәлләкүм түфлихүүн».

Мәгънәсе: *«И мөэминнәр! Тормыш авырлыкларына, дин мәшәкатьләренә, төрле казаларга вә дошманнарның һөҗүмнәренә сабыр итегез! Нинди генә авырлыклар килсә дә, ул авырлыкларны бергәләп күтәрегез, чыдамлы-сабыр булыгыз, динегезне саклауда берләшеп, дошманга каршы нык торыгыз вә дәхи Аллаһы Тәгаләдән куркыгыз, шаять, өстенлек табарсыз, бәхеткә ирешерсез!»*

Югарыда әйтелгәнчә, Аллаһы Тәгалә безне шундый күршеләр, ачлык, малларны киметеп, җимеш бакчаларындагы җимешләрне азайтып һ.б. нәрсәләр белән сынарга мөмкин. Тик соңыннан сабыр итүчеләргә Хак Тәгаләнең әҗер-саваплары вәгъдә ителә. Бу сүзләргә дәлил буларак «Шура» сүрәсенең 43 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Әгәр берәү кешеләрнең золымына һәм җәзасына сабыр итсә, чыдаса, аларны кичерсә, үч алмаса: дөреслектә, бу кеше олуг әҗер-савапларга ирешер».

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәламнең хәдисендә болай диелә: «Көчле кеше көрәшкәндә иптәшләрен җиңгән кеше түгел, көчле кеше — ачуы чыккан вакытта сабыр итеп, үз ачуын җиңгән кеше». Мөэмин кеше үз гомерен Хак Тәгаләгә тапшырса, ягъни Аңарга буйсынса, яхшы гамәлләр кылса һәм бәла-казалар килгәч сабыр итсә, Аллаһының рәхмәтен вә җәннәтен табачак, иншаллаһ.

— **Күршем минем белән бик дорфа сөйләшә. Башка берәр кеше белән сөйләшкәндә, «моннан да яхшы кеше юктыр», дигән фикердә каласың. Мондый икейөзле кешеләр элек тә булдылар микән?**

Дауд галәйһис-сәлам хәзрәти Локманга әйткән:

— Бер бәрән суй да, аның тәнендәге ике иң яхшы өлешне миңа китер!

Хәзрәти Локман кушканнарны эшли һәм тел белән йөрәкне алып килә.

— Ә хәзер иң начар өлешләрен китер!

Хәзрәти Локман кабат тел белән йөрәк күтәреп килә. Дауд галәйһис-сәлам моның сәбәбен сорагач, ул болай ди:

— Әгәр йөрәк белән тел яхшы булсалар, бөтен тән яхшы булыр, ә инде алар начар икән, тән дә яхшы була алмас.

Ислам дине күрсәткән юл — күркәм тел белән яхшы гадәтләргә чакыру, начар, бозык эшләрдән үзеңне һәм телеңне тыю. Дөньяның матур, тормышның ямьле, ризыкның тәмле булуы, күршең белән тату яшәү, тәмле тел белән аралашу, тыныч дуслык, бер-береңә ярдәмле, рәхимле, шәфкатьле булу да шул телгә килеп тоташа. Ислам шуны таләп итә. Ислам күрсәткән юл белән гамәл итсәк, дөньяда да, ахирәт йортында да Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешүгә сәбәп булачак.

— **Миңа трамвайда бер күңелсез вакыйганың шаһиты булырга туры килде. Олы яшьтәге бер кешедән кондуктор акча сорагач, ул кеше барча кесәләрен актарды, төсе китте: «Пенсия кенәгәсе белән юл йөрү билетым өйдә калган, үзем белән акчам да юк», — дигәч, кондуктор аны оятсыз сүзләр белән сүгеп, эткәләп төшереп калдырды. Бер-беребезгә игътибарлылык шушы буламы?**

- Риваять кылына: Мәлик ибне Динар исемле галим бервакыт диңгезгә сәяхәт кылырга чыга. Бераздан көймә хуҗасы сәяхәт өчен барысыннан да акча җыя башлый. Ләкин Мәлик ибне Динар кесәсендәге акчаны таба алмый һәм хуҗага әйтә:

— Сез гафу итегез, минем акча янчыгым өйдә калган, мин кайткач та сезгә түләрмен.

Көймә хуҗасы аңа ышанмый:

— Синең әкиятләреңне ишетергә теләмим, акчаны хәзер үк бир!

Ләкин мөхтәрәм кеше, әлбәттә, акчаны бирә алмый һәм аны көймә хуҗасының ярдәмчеләре үлем хәленә җиткергәнче кыйныйлар, соңыннан диңгезгә ыргытырга телиләр. Шул вакыт гаҗәп бер хәл була, Аллаһының рәхмәте белән, диңгездәге балыклар башларын чыгара — һәрберсенең авызында бер динар акча була. Мәлик ибне Динар акчаларны җыеп ала да көймә хуҗасына бирә.

Бу күренешне күргән матрослар, көймәдә ял итүчеләр, юлчылар аның изге, галим кеше булуын аңлыйлар һәм кылган эшләренә үкенәләр. Көймә хуҗасы Мәлик ибне Динардан түбәнчелек белән гафу үтенеп, көймәдә күпме теләсә, шул чаклы кала алуын әйтә. Ләкин ул башкача хәл итә:

— Тынычлыкта, иминлектә калыгыз, мин сезнең белән башка кала алмыйм, — дип, көймәдән диңгезгә төшеп су өстеннән атлап китә. Нәкъ менә шушы вакыйгадан соң аны Мәлик ибне Динар дип йөртә башлыйлар.

Пәйгамбәр галәйһис-сәламнең хәдисе бар: «Бер кавемнең хөрмәтле кешесе, начар киемнән булса да, сезнең яныгызга килсә, сез аны хөрмәт итегез!»

**Мәгълүмат Региональ Диния нәзарәте вәкилләре катнашында тупланды.**